**ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422350, штп. Апас, Советская урамы,

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 258 от 08.12.2025

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләре турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Гражданнар оборонасы турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2025 елның 23 июлендәге 240-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм аларны әзер килеш саклап калу турында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 7 декабрендәге 423 номерлы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләре һәм аларны саклап калу хакында нигезләмәгә, 3 пунктның бишенче абзацында «хәрби конфликтларда яисә әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда» сүзләрен «куркынычлар барлыкка килү нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 20 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Җитәкче** **Б.Н. Әхмәтҗанов**